Тел җәмгыять яшәеше белән тыгыз бәйләнгән. Телдә кеше эшчәнлегенең төрле яклары һәм эш вакытында аның җәмгыять, табигать, әйләнә-тирә белән мең төрле мөнәсәбәтләре чагылыш таба. Әлеге мөнәсәбәтләрне тел берәмлекләренең семантик үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә генә ачыкларга мөмкин. Татар телендә кеше һәм аңа якын тирәлектәге предметларның тышкы билгеләрен, пространствога бәйле төрле мөнәсәбәтләрен характерлый торган сыйфатларны махсус өйрәнгән фәнни хезмәтләр юк. Мәгълүм булганча, предметлар доминант параметр буенча характерланалар. Мәсәлән, *биек йорт,* йорт төзелешенә куелган стандарттан биегрәк булып күренә, әгәр йортлар зур һәм озын булсалар, аларны тасвирлаганда *биеклек* параметры кулланылмый [1, 3]. Ономасиологик алым предметларның сыйфатын капма-каршы юнәлештә, ягъни чагылыш планыннан эчтәлек планына таба өйрәнүне күздә тота. Эчтәлек планына семасиологик якын килү, нигездә, сыйфатларның билге белдерү үзенчәлеген ачыклауга корыла. Әлеге мәкаләнең фәнни яңалыгы – кеше тирәлегенә бәйле булган предметларның күләмен белдерә торган билгеләрне ономасиологик алым кулланып, чагыштырма аспектта тикшерү. Димәк, хезмәтнең өйрәнү объекты итеп – сыйфатлар, тикшерү предметы буларак сыйфатларның эчтәлеге һәм тасвирланышы алынды. Кешеләрнең көнкүрешенә, яшәү тирәлегенә бәйле киңлек параметрларларын анализлауда

Г.И. Кустова тарафыннан тәкъдим ителгән алым кулланылды [4].

Беренче чиратта кешегә «якын тирәлекне»не тәшкил итә торган параметрик сыйфатларга тукталыйк. Кием-салым, бизәнү әйберләре контакт параметрлары булып саналалар [2]. Әлеге предмет параметрлары турыдан-туры кешенең үзенә карата кулланылмый, әмма алар прототипик үлчәү билгесенә ия булып торалар. Ягъни кешеләр бу әйберләрне кулланганда, үзләренең гәүдә үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларның озынлыгына, киңлегенә, зурлыгына игътибар итәләр. Мәсәлән, озын муенсалар муен үзенчәлекләренә карап сайлана, озын күлмәкләр яки чалбарлар кигәндә буй һәм аяк озынлыгы исәпкә алына. Мисал өчен **бизәнү әйберләре**н карап үтик:

*Итәк очы алтын чачаклы ак атлас күлмәк, алтынсу ефәк билбау, җиң очлары, яка турлары ука белән чигелгән куе кызыл төстәге бәрхет камзул кигән, муенга затлы каптырма белән эләктерелгән, эре тамгалы энҗе-бриллиантлар белән зиннәтләнгән **киң муенса**, башына җем-җем килеп торган, энҗе-бриллиантлар белән бизәлгән, очы уң якка салынып торган калфак кигән* (М. Галиев. Талисман) [10].

*Ак батист яулыгын кара кашлары өстеннән генә артка кайтарып бәйләгән, якасы ачык, кыска җиңле тар күлмәк киеп, җыерчыклы муенына вак мәрҗәннән **кечкенә муенса** таккан, симез беләгенә кара көмеш беләзек кигән* (Ә. Еники. Саз чәчәге) [10].

*If their complexion was their most celebrated feature, then perhaps a **long necklace** of perfect pearls* (8S2) [6].

*Bare shoulders and arms; a heavy gold and ebony bracelet; an enormously **long necklace** of what looked like sapphires, though I presumed they must be paste* (G13) [6].

Югарыда телгә алынган бизәнү әйберенең озынлык параметры кешенең муен үзенчәлекләренә бәйле рәвештә карала. Татар телендә *муенса* сүзе 109 тапкыр очрый, әмма параметрик сыйфатлар белән кулланылган очракка ике генә мисал табылды: *киң муенса, кечкенә муенса.* Инглиз телендә, мәсәлән, *муенса* параметрик сыйфат белән бик сирәк характерлана: *long necklace* ике урында күзәтелде, ә *short necklace* сүзтезмәсе бөтенләй очрамады. Шулай итеп, татар телендә муенса өчен озынлык параметры мөһим роль уйнамый. Бу исә халык аңында традицион рәвештә кулланылып килгән нинди дер стереотип озынлык барлыгын искәртә.

**Кием-салым**

*Кәрим абый киңәшен истә тотып, өстемә киясе нәрсәләрне сайлап алдым: кара бәрхеттән тар гына **озын күлмәк**, биек үкчәле туфлиләр, кечкенә энҗеле калфак* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хәтирәсе) [10].

М*әрьямбану бөтен тәнен каплап торган **озын күлмәк** кигән, башына, чәч муены күренмәслек итеп, ак яулык бөркәнгән* (Ф.Бәйрәмова. Соңгы намаз) [10].

*Ә яныңда торган авыл кызының черкиләргә исе дә китми, бары тик ара-тирә генә болай да **кыска күлмәк** итәген күтәреп, ак балтырларына кунган әдәпсез черкинең башына җитә* (Н. Әхмәдиев. Амбирак, яки кара каен кыйссасы) [10].

*Ак төстәге **кыска чалбар** кигән, җиңсез блузкасын да җилкәсенә эленгән ике тар тасма гына тотып тора* (М. Әмирханов. И кылган догам минем) [10].

*Бәлки, алар колхозының сыерларыннан сауган сөтләр дә менә шулай шешәләр белән монда киләдер дә, аның кем кулыннан чыкканын уйлап тормастан, тездән югары **кыска чалбар** кигән, кара күзлекле, җонлы балтырлы шушы адәмнәр эчеп куялардыр* (М. Мәһдиев) [10].

*Sounds like she's got a flipping **long dress** on and a straw hat* (KCE) [6].

*We had works big ball in the wintertime, when you went with your **long dress** on, and your gloves, you know your* (H05) [6].

*Mrs Lynde looked at the thin little girl in the **short dress**, with her freckled face and red hair* (FPT) [10].

*Lower at the back, the **short dress's** absolute simplicity contrasted effectively with the extravagant colour, a deep rich crimson* (H9L) [6].

*Because he always had **long trousers** that went over his boots, and they were you know, very wide* (G64) [6].

(2) *They were real grown-up **long trousers** exactly like those worn by the boys at the big school* (ACW) [6].

Гадәти хатын-кыз киеме озынлыкны билгели торган параметрик сыйфатлар белән билдерелә, югарыда искәртелгәнчә, алар кешенең буй озынлыгына карап билгеләнәләр. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, һәр ике телдә дә уңай параметрлы сыйфатлар, тискәре параметрик сыйфатлардан аермалы буларак, 4-5 тапкыр күбрәк кулланылган. Татар һәм

инглиз телләрендәге параметрик сыйфатларның кулланылыш ешлыгын чагыштырма планда анализлау нәтиҗәләре бу төр сыйфатларның инглиз телендә 2 тапкыр кимрәк кулланылуын күрсәтте. Мисалларны карап китик: *long dress* – 22 тапкыр, татар телендә: *озын күлмәк* – 39 тапкыр. *Тискәре* параметрлы сыйфатларларның кулланылыш ешлыгына килгәндә, алар ике телдә дә бертигез дәрәҗәдә очрый: *short dress* – 5 тапкыр*, кыска күлмәк* – 7 тапкыр. Шунысын да билгеләп китү мөһим: татар телендә күлмәк озынлыгының стандарт параметрлары инглиз телендәге параметрлардан күпкә артыграк, бу исә татар халкының традицион киемнәре арасында озын күлмәкнең уңай коннотациягә ия булуына бәйле.

Чалбар, гадәти ир-ат киеме буларак, очраклы рәвештә алынмады, чөнки аның озынлыгы гәүдәнең боттан алып тубыкка кадәр булган өлешенә карап билгеләнә. Татар телендә чалбарны озынлыгы буенча характерлау бик аз күләмдә бирелгән: *озын чалбар* – 1 тапкыр, *кыска чалбар* – 6 тапкыр. Инглиз телендә тискәре параметрик сыйфат 2 тапкыр артыграк кулланылган: *long trousers* – 13 тапкыр, *short trousers* – 29 тапкыр. Әлеге сыйфатның кулланылышы тискәре бәя бирүне күз алдында тота, чөнки чалбар озынлыгының стандарт параметры боттан алып тубыкка кадәр булган ара озынлыгына туры килергә тиеш.

***Баш киеме***

*Тавышка* ***зур мамык шәл*** *ябынган әнисе ут кабызган икән* (С. Шәрипов. Хушлашмыйм) [10].

*Яңагын* ***зур яулык*** *белән бәйләгән Шәйхетдинов керә* (Т. Гыйззәт) [5].

*Башына ул чәчен бергә туплап* ***кыска гына яулык*** *бәйләп куйган, өстенә эре чәчкә төшерелгән кыска итәкле ситсы күлмәк һәм иркен балаклы озын чалбар – спортсменнар чалбары киеп куйган иде* (Н. Фәттах. Сайланма әсәрләр) [10].

*Why did they last minute put this* ***long scarf*** *round her neck, hmm?* (8S2) [6].

*All I know is he he has big, protruding eyes and he wears a funny-looking,* ***short****,* ***white scarf*** (ACW) [6].

Тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, инглиз теле белән чагыштырганда, татар телендә хатын-кыз баш киеменең күп кулланылган булуы ачыкланды, әлеге факт татар халкының милли һәм дини үзенчәлекләре белән аңлатыла. Уңай параметр сыйфатларыннан *зур яулык* (шәл) – 17 тапкыр, кире параметрик сыйфаты *кыска яулык* – 4 тапкыр очрый. *Кечкенә яулык* кебек сүзтезмәләр дә күзәтелде, әмма аларда *яулык* сүзе кулъяулык мәгънәсендә кулланылган. Биредә шуны да искәртеп китү мөһим: татар хатын-кызлары яулык яки шәл өстеннән калфак та кигәннәр. Калфак берәмлеген ачыклап килгән сыйфатлар, гадәттә, әлеге милли баш киеменең бизәлешен, төсен, кыйммәтлелеген ассызыклыйлар; әмма, сирәк кенә булса да, *кечкенә, нәни* кебек тискәре параметрик сыйфатлар белән кулланылган очраклар да бар:

*Кызның башында – төсе һаман үзгәрмәгән* ***нәни*** *яшел* ***калфак*** (Р. Гариф Үлмәсбикә) [10].

***Кечкенә*** *генә* ***калфак*** *кия, атасы күрмәгәндә мандолина уйнап та җибәрә* (Г. Ибраһимов. Яшьләр) [10].

Инглиз телендә *шарф* еш кына хатын-кызның баш киеме буларак очрый, ул күптөрле сыйфатлар белән билгеләнә, әмма аның параметрик сыйфатлар белән кулланылышына мисаллар бик аз табылды. Шарф, нигездә, озынлык параметры буенча характерлана [8, 9]. Безнең күзәтүләрдә *озын шарф* уңай параметрик сыйфат булып санала, ул 6 тапкыр очрады, тискәре билгегә ия булган *кыска шарф* сүзтезмәсе 3 тапкыр очрады.

**Аяк киеме**

*Кысып торган яисә артык* ***зур аяк киеме*** *сәламәтлек өчен зыянлы* (А. Ситдыйкова. Сәламәтлек – үкчә астында!) [10].

*Аягына кап-кара* ***зур итек****, өстенә алама сырма, башына йолкыш бүрек кигән мыеклы ир стройдан йөгереп чыга да, тезен кочаклап, җепшек карга иелә* (С. Шәрипов) [10].

*She thinks she's tall. Look at him* ***big shoes*** *So what, so what say it right here* (KPE) [6].

*Half consisted of a short, black skirt and plump legs tapering to absurdly* ***small shoes*** (GW3) [6].

*The only blots on the landscape were a pair of* ***small shoes*** *beside the Aga and a nylon ski– jacket airing on the back of a chair* (JYC) [6].

Безнең фикеребезчә, ир-ат һәм хатын-кыз аяк киемнәренә аерым анализ ясау ихтыяҗы юк, чөнки ике очракта да аяк киеменең үлчәме аяк табаны зурлыгы белән билгеләнә. Шуның өстенә, татар телендә дә, инглиз телендә дә аяк киеменең зурлыгын характерлау бик сирәк күзәтелә: *big shoes* – 1 тапкыр, *small shoes* – 2 тапкыр, *зур аяк киеме* – 6 тапкыр*, кечкенә аяк киеме* – 1 тапкыр. Инглиз теленнән аермалы буларак, татар телендә *итек* сүзе бик еш кулланылган (551 тапкыр). Алар арасында озынлык үлчәме белән тасвирланган бер генә

параметрик сыйфат табылды һәм әлеге параметр аякның тубык озынлыгына карап билгеләнә. Димәк, аяк киеме һәм аның үлчәме, нигездә, аяк табаны параметрына тәңгәл.

Кунычлы аяк киемнәрендә, мәсәлән, *итек* сүзендә, параметрик сыйфатларның бүтән төрләрен дә күрергә мөмкин:

*Лесниковның аягында – **озын итек**, буыннары ялгана торган спиннинг тагылган җебен беләгенә элгән, җылырак кингән* (С. Шәрипов. Хушлашмыйм) [10].

*Итек* сүзе татар телендә, бик еш күзәтелүенә карамастан (551 тапкыр), параметрик сыйфатлар белән сирәк кулланылган. Соңгы мисалда тәкъдим ителгән параметрик сыйфат (*озын итек*) аякның тубык озынлыгына карап билгеләнә. Татар теленә бәйле тагын бер кызыклы үзенчәлекне искәртеп китү зарур: биредә *башмак* (59 тапкыр), чүәк (24 тапкыр) кебек аяк киемнәре бик күп очрый, әмма аларның параметрик сыйфатлар белән кулланылган очраклары күзәтелмәде.

**Ризык**

«Ризыкны матди яктан карап була, аның үз авырлыгы бар, кеше аны үз өстендә йөртмәсә дә, эчендә йөртә,» – дип искәртә И.Г. Кустова [4: 144]. Ризыкларны характерлый торган гомуми билгеләр җыелмасы бар, шул сәбәпле алар өч үлчәмле параметрик сыйфатлар белән сирәк белдереләләр. Мәсәлән, *зур торт* дигәндә, әлеге ризыкның зурлыгына түгел, бәлки бәйрәмнең масштабына басым ясала. Татар һәм инглиз телләрендә *big mac, вак бәлеш* сүзтезмәләре бик еш очрый, әмма бу очракта *big, вак кебек* сыйфатлар әлеге ризыкларның зурлыгын белдерми, чөнки һәр икесе ризык атамасы составында кулланылалар.

*Well we don't have it on Sunday because we always have a grea*t ***big lunch*** (KBB) [6].

*I can't eat it I don't think so he had a **big lunch*** (KCV) [6].

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, инглиз телендә *big* сыйфатын Макдональдс ризыклары исемлегедә бик еш очратырга мөмкин *big mac, big tasty h.б.* Кулланылыш ешлыгына килгәндә, инглиз теле корпусында иң күп очрый торган сүзтезмә – *big mac*, ул 41 тапкыр кулланылган, икенче урында 6 мәртәбә күзәтелгән *big lunch* сүзтезмәсе. Алар икесе дә уңай параметрик сыйфат булып саналалар.

Бәйрәм торты да инглиз телендә зур үлчәмнәр белән сирәк характерлана: *big cake* – 6 тапкыр, ә *small cake* 12 тапкыр очрый. Күргәнебезчә, биредә тискәре параметр сыйфаты өстенлек итә, әмма кечкенә үлчәмне белдерә торган *cup cake* сүзтезмәсенең барлыгын да искәртеп китү мөһим.

*Табын уртасына хуш исләре аңкып торган чөмәкле **зур бәлеш** чыгарылды* (Р. Низами. Без яшибез) [10].

*Квартирга кунак егет кайтасы булгач, Гайнелвафа карчык бозауны абзарга чыгарган, сап-сары итеп баскычларны, идәннәрне юган, **вак бәлеш** пешергән иде* (М. Мәһдиев. Фронтовиклар) [5].

*Карчык кишерне турап, аңардан **зур бәлеш** пешергән* (С. Сәүбанова. Әкиятләр) [10].

*Ак әби иртән Гыйлемдарны **вак пәрәмәч** белән сыйлады* (А. Тимергалин. Караурман аша) [10].

***Ва**к кына **күмәч** яки **бавырсак*** (Гаяз Исхакый. Кәҗүл читек) [10]. Мисаллардан күренгәнчә, татар телендә ризык параметрларын билгели торган сыйфатлар арасында *вак* сыйфаты өстенлек итә, әлеге сыйфат 2692 тапкыр очрый. Параметрик сыйфатлар күбесенчә (*зур бәлеш, вак бәлеш*) ризык атамасы составында кулланылганнар. Соңгы өч җөмләдә билгеләнгән сүзтезмәләрдә генә (*зур бәлеш, вак пәрәмәч, вак бавырсак, вак күмәч)* ризыкның параметрик билгесен белдереп килгәннәр.

Шулай итеп, тикшерү барышында тоташ сайлау методы ярдәмендә тупланган параметрик сыйфатлы 300 сүзтезмәгә анализ ясалды һәм аларның күпчелек өлешен ризык атамалары тәшкил итә.

Татар телендә мәҗлеснең әһәмиятен, зурлыгын билгели торган төп ризык булып, инглиз теленнән аермалы буларак, торт түгел, ә бәлеш санала. Димәк, логик яктан ул уңай параметр сыйфаты белән характерланырга тиеш, әмма *зур бәлеш* сүзтезмәсе нибары 5 тапкыр гына очрады. Безнең фикеребезчә, әлеге милли ризык атамасының исеме үк аның зурлыгын билгели. Бу гипотеза тискәре параметр сыйфатының *вак бәлеш* сүзтезмәсендә ешрак куллануын аңлата: *вак бәлеш* – 16 тапкыр. Калган сүзтезмәләр бик сирәк күзәтеләләр, мәсәлән, *вак пәрәмәч* – 3 тапкыр. *Зур пәрәмәч* сүзтезмәсе бөтенләй кулланылмый. Биредә шуны да искәртеп китү мөһим: камыр ашларын характерлаганда *вак* сыйфаты аларга тискәре бәя бирми, бары тик аларны нейтраль яктан гына тасвирли. Калган очракларда, мәсәлән, башка төрле ризыкларга бәя биргәндә,

тискәре параметр сыйфатлары, гадәттә, негатив бәя буларак күзалланалар.

**Кешенең тән төзелеше**

Параметрик сыйфатлар белән гадәттә кешенең гәүдәсе дә, тән әгъзалары да тасвирлана. Кешенең гәүдә зурлыгы *озын* һәм *таза* кебек сыйфатлар ярдәмендә характерлана, әмма бирелә параметрик характеристиканың кешенең үз күзаллавыннан, үз-үзен ничек кабул итүеннән чыгып билгеләнүен истә тоту мөһим. Кайбер мисалларны карап китик:

***Озын чәч** үстерергә рөхсәт итмиләр иде ул чакта* (З. Мәхмүди. Хыялый) [10].

*Дөрес, кайчагында кистереп атасы килгән минутлары да була кызның, янәсе, **кыска чәч** булса, мәшәкате әзрәк* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим) [10].

*Зур күзле, коңгырт калын толымлы, төз **озын аяклы**, ап-ак тәнле бер кыз икән* (М. Мәһдиев. Фронтовиклар) [10].

*Биек күтәртмәле аяк киеме кигән хатын-кыз үзенең тәбәнәк буйлы һәм **кыска аяклы** икәнен күрсәтеп йөри (Р. Батулла. Сайланма әсәрләр)* [10].

*Эчендәге тышында булган, уйлаганы шундук теленә чыккан Нурия бала чакта торып калды, аның урынына кинәт сузаеп киткән, **озын куллы**, **озын аяклы, озын муенлы** (абау!) берәү пәйда булды* (Г. Якупова. Ерткыч каны) [10].

*Җыелганнар ярым көлемсерәп бер-берсенә караштылар, түрдә утырган, шәрә тәне зәңгәр сурәтләр белән бизәлгән, киң күкрәкле, **кыска куллы** бәндә черт итеп төпчеген почмакка очыртты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?) [10].

Югарыда искәртелгәнчә, озынлык, биеклек һәм киңлек – контактка бәйле булмаган билгеләр. Аларны очратып була. Әгәр предмет озынлык параметрына туры килсә, ул *озын* сыйфаты белән белдерелә. Күп кенә предметлар чагыштыру нәтиҗәсендә генә озынлык билгесенә ия булалар. Мәсәлән, *озын толым* сүзтезмәсен алыйк, ул икенче бер толымнан озынрак булуы белән аерылып тора:

*Кылану гына булган икән, бераздан каядыр җыенгандай кинәт тураеп, **озын** кара **чәч толымнарын** рәтләргә керешә* (З.Мәхмүди. Серле кунак) [10].

*Икесендә дә **кыска толым**, аякларында килешле кәттә чүәкләр, өсләрендә җиңел чуар күлмәк* (Н. Каштанов. Паромда) [10].

Инглиз телендәге мисалларга игътибар итик:

*He's got **long hair** and all* (KB1) [6].

***Short hair*** or ***long hai**r or just a man*? (KCV) [6].

***Short hair** like a bit of a moron?* (KDM) [6].

*You'll grow up to be an ugly wizened little monster with **short arms** and a big head* (ACW) [6].

*On the landing a new thought occurred to her and she re–entered, her **long arms** swinging, her face screwed up with anger* (ASS) [6].

*It was summer and the only time the air moved was when Zervos waved his **short arms** or a truck went past outside* (C86) [6].

*His big body and large head topping the back of it while his **short legs** hardly touched the floor* (CK9) [6].

*I can imagine you in a tennis dress. You have such **long legs**." My knees are knobbly,' she said firmly* (A0R) [6].

Ике телдәге күзәтүләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин.

Кеше тәне әгъзалары атамалары һәм параметрик сыйфатлардан торган сүзтезмәләр төркеме ике телдә дә күп кулланылган. Алар кешенең тышкы кыяфәтен аерым бер билге буенча характерлыйлар. Теге яки бу тән әгъзаларының билгеле бер эстетик нормалардан чагыштырмача зуррак яки кечерәк булуы кабул ителгән стериотипны боза, мәсәлән, *зур башлы, озын колаклы һ.б.* Этика нормалары теге яки бу тән әгъзасының озынлык параметрына туры килмәвен бәяләмичә, нейтраль рәвештә аңлатуны күздә тота.

Инглиз телендә дә кешенең тән әгъзаларын озынлык параметры ягыннан тасвирлый торган сыйфатлар саны байтак [7]. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, әлеге телдә, нигездә, уңай параметрга ия булган сыйфатлар өстенлек итә. Мисал өчен, кешенең *кул озынлыгын* белдергән сыйфатларның 3 тапкыр, *аяк озынлыгын* чагылдырган сыйфатларның 5 һәм *чәч озынлыгын* тасвирлаганнарының 2 тапкыр артыграк кулланылышы күзәтелә.

*long hair* – 271 тапкыр; *short hair* – 109 тапкыр;

*long arms* – 33 тапкыр; *short arms* – 11 тапкыр;

*long legs* – 155 тапкыр; *short legs* – 30 тапкыр.

Сүзтезмәләрнең күпсанлы булуын кешеләрнең үз-үзләренә һәм тирә-юньгә игътибарлы булулары белән аңлатырга мөмкин.

Татар телендә кешенең тән әгъзаларын тасвирлый торган параметрик сыйфатларның

кулланылыш ешлыгы, инглиз теле белән чагыштырганда, 5 тапкыр кимрәк:

*озын чәч* – 47 тапкыр; *кыска чәч* – 11 тапкыр;

*озын аяклы* – 34 тапкыр; *кыска аяклы* – 20 тапкыр;

*озын куллы* – 19 тапкыр; *кыска куллы* – 1 тапкыр.

Шунысы да игътибарга лаек: татар телендә аякны тасвирлый торган тискәре параметрик сыйфатларның күпчелек өлеше теге яки бу предметка (мәсәлән, *кыска аяклы өстәл* һ.б.) яки хайваннарга (*кыска аяклы эт яки сыер* һ.б.) карата аеруча еш кулланылган.

Татар мәдәниятендә кешенең тышкы кыяфәтенә зур игътибар бирү кабул ителмәгән, кеше кыяфәтенә караган параметрик сыйфатларның сан ягыннан ким булуы да нәкъ менә шушы үзенчәлеккә бәйле дип саныйбыз.

Кешенең **йөз кыяфәте** төрле сыйфатлар белән характерлана ала. Йөз-кыяфәтнең гомуми үлчәме аның башка өлешләренең, мәсәлән, *зур (тар, киң) маңгай, зур (кечкенә) күз, зур (озын, почык) борын* параметрларын билгели торган күрсәткеч булып тора. Китерелгән мисалларда *киң, зур, озын* кебек параметрик сыйфатлар йөз-кыяфәт параметрыннан (зурлыгыннан) чыгып билгеләнгән.

*Теге-бу турында сөйләштеләр, көлештеләр, ләкин яңадан музыка уйный башлагач та,* ***зур борынлы*** *егет беренче булып Рафиганың кулыннан тотып та алды, җилтерәтеп, бөтерелдереп, уртага кереп тә китте* (Н. Фәттах. Сайланма әсәрләр) [10].

*Гуд бай! – дип хәтәр янады калун балта йөзедәй рәхимсез чырайлы,* ***зур борынлы*** *латыш һәм куркытып чыгып та киттеләр* (Х. Камалов. Сайланма әсәрләр) [10].

*Дүрт ай узгач та, күрше Миңлебикә абыстай Татаның үзеннән ун яшь чамасы яшьрәк, ак кына чырайлы, бәрәңге алмасы кебек түгәрәк* ***кечкенә борынлы****, яшькелт күзле бер хатынны ияртә керде* (Ә. Баян. Төлке тоту кыен түгел) [10].

*Чөнки бездә хәзер* ***кечкенә борынлы*** *яһүдләр, зәңгәр чәчле татарлар, кысык күзле урыслар һәм сап-сары башлы негрлар күбәйде* (К. Кәримов. Телеңне күрсәт...) [10].

*Аскарак салынган иреннәре белән* ***зур авыз*** *эчендә тезелгән ак, озын тешләр, ут уйнап торган ялкынлы* ***зур күзләр****, бигрәк тә, ут чыгаргандай каты, үткен, тиз баса торган йомры, кечкенә ялтыр тояклар аның бу киң далада бик күп җылкыларга алын бирмәс йөгереклеген күрсәтәләр* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы) [10].

Үзе кебек үк ***зур күзле, олырак авызлы*** томрап торган улы дөньяга килгәндә, Әхтәри Берлин янында, бәләкәй генә зиратта, чит илнең салкын туфрагында ята иде инде (А. Гыйләҗев. Тәрәзәләр) [10].

***Кечкенә авыз***, сусыл иреннәр, гүя ул салам кабып затлы коктейль йотарга гына яратылган (С. Шәрипов Хушлашмыйм) [10].

*Рамил ул арабызда иң озын буйлы, зур башлы,* ***зур күзле****, киң иңсәле таза һәм батыр малай* (Р. Фәизов. Без – өч дус) [10].

*Ул мәҗлестә* ***кечкенә күзле*** *бер бала бар иде* (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр) [10].

*Чиертсәң кан чыгарга торган кып-кызыл чырайлы, дуңгызныкы кебек кенә* ***кечкенә күзле*** *юан майор акыра икән* (И. Сираҗи. Бер утыру – бер гомер) [10].

Татар телендә уңай параметрлы сыйфатлар *борын* һәм *күзләрне* тасвирлаганда аеруча күп очрый, аларның *авыз* һәм *колак* кебек әгъзаларны белдергән параметрик сыйфатлардан аермалы буларак, 3 тапкыр ешрак кулланылган булуы ачыкланды.

*зур борынлы* – 31 тапкыр; *кечкенә борынлы* – 5;

*зур күзле* – 34 тапкыр; *кечкенә күзле* – 5; *бәләкәй күзле* – 0;

*зур авыз* – 11 тапкыр; *кечкенә авыз* – 1 тапкыр;

*зур колаклы* – 11 тапкыр; *кечкенә колаклы* – 2 тапкыр.

Инглиз телендәге мисалларны карыйк:

*He's got a* ***big nose*** *got big ears* (KP3) [6].

*Boyfriend said I'm a common cow and have a got a* ***big nose*** (KPG) [6].

*Moxie, was curly and glossy, his face with high cheek bones and* ***small nose*** *and small sensuous mouth and dark blue eyes, had resumed its glowing charm* (APM) [6].

*Her features were classically beautiful: the perfectly structured high cheekbones, a* ***small nose****, sensual mouth and mesmerizing oval– shaped green eyes* (ECK) [6].

*She don't say nothing to me, she just looks at me with these* ***big eyes*** *(*A74) [6].

*Dark girl dressed in scarlet who had a big head,* ***big eyes*** *(her best feature), a big nose and a very big voice* (ABW) [6].

*A slow deliberate talker, he fixed his* ***small eyes*** *on the subject he was conversing with, as though exerting a hypnotic effect* (ARK) [6].

*Cynthia and her father coloured hotly, Basil glowered, and Mrs Blessington– Dalrymple's* ***small eyes*** *snapped angrily* (BMU) [6].

*I love your hairy chest, I love your bi– but I love your* ***big ears****, I love you* (KB8) [6].

*Big nose,* ***big ears****, big, big mouth*! (KDA) [6].

*God had never invented a woman with* ***small ears****!* (KD8) [6].

*It stuck tiny thumbs in* ***small ears****, wagged its fingers, and put out its tongue* (CEU) [6].

Инглиз телендә йөз-кыяфәтне тасвирлый торган сүзтезмәләр төркеме киң таралыш алган. Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, уңай параметрик сыйфатлар йөз-кыяфәтнең барлык өлешләрендә дә бертигез кулланылалар. Тискәре параметрга ия булган сыйфатларны *борын, колак* һәм *авыз, күз* кебек әгъзаларны тасвирлаганда күзәтергә мөмкин, әмма алар, кулланылыш ешлыгы ягыннан, уңай параметрик сыйфатлардан күпкә калышалар. Мәсәлән, *борын*га бәйле тискәре сыйфатлар – 4, *колаклар*ны тасвирлаганнары – 10*, авыз*ны сурәтли торганнары 3 тапкырга кимрәк очрый. Бары тик *күзл*әр белән бирелгән сүзтезмәләрдә генә тискәре параметрик сыфатларның, уңай параметрик сыйфатлар белән чагыштырганда, 3 тапкырга артыграк кулланылышы ачыкланды:

*big nose* – 27 тапкыр; *small nose* – 7 тапкыр; b*ig eyes* – 33 тапкыр; *small eyes* – 21 тапкыр; *big ears* – 49 тапкыр; *small ears* – 4 тапкыр; *big mouth* – 50 тапкыр; *small mouth* – 15 тапкыр.

Шулай итеп, инглиз телендә кешеләрнең йөз-кыяфәтен тасвирлауга зур игътибар бирелә һәм аның аерым өлешләре параметрик сыйфатлар ярдәмендә җентекле рәвештә тасвирлана.

Ике телнең дә кеше тирәлегенә якын булган параметрик сыйфатларын тикшергәннән соң, түбәндәге **нәтиҗәләр** билгеләнде:

- Параметрик сыйфатларның семантик үзенчәлекләре гаять катлаулы. Биредә, иң беренче чиратта, теге яки бу предмет билгесенең стандарт параметрларын ачыклау мөһим. Стандарт билгеләргә туры килсә, предметның сыйфаты уңай характерлана, туры килмәсә, тискәре параметр буларак карала. Әмма бу параметрларны һәр халык үзенең күзаллауларыннан чыгып билгели. Мәсәлән, татар халкының милли ризыгы булган *вак бәлеш* атамасында кулланылган тискәре параметрик сыйфат биредә ризыкның үлчәмен белдерми, ләкин башка халык аны нәкъ менә тискәре параметрик сыйфат итеп кабул итәргә мөмкин.

Кайбер предметларның параметрик билгеләре зур һәм кечкенә белән генә чикләнми, аларга *киң, тар, озын, кыска* кебек сыйфатлар да хас була. Параметрик сыйфатлар күбрәк булган саен, предметның эчтәлеге тулырак ачыла. Биредә бер үк параметрларны белдергән синонимик (*зур, олы, дәү; кечкенә, бәләкәй, нәни*) яки антонимик сыйфатларны (*зур – кечкенә; озын – кыска*) да истә тотарга тиешбез. Шуңа күрә, югарыда искәртелгәнчә, параметрик сыйфатларны ономасиологик алым кулланып тикшерү зур әһәмияткә ия булып тора. Бу алым параметрик сыйфатларның күчерелмә мәгънәләрдә дә кулланылышын ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, әгәр тән төзелешенә караган мисалларны алсак, татар теле корпусында *киң авызлы, тар авызлы, зур авызлы* кебек мисаллар кешегә карата түгел, ә башка предметларга карата кулланылганнар. Мәсәлән: *Кечкенә генә,* ***тар авызлы*** *кувшин иде ул* (Р. Сәгъди. Ирдәүкәләр) [10]. *Шулай да табактай* ***олы авызлы*** *кәкре торбаларны һәм аккош муеныдай сыгылмалы скрипкаларның ни икәнен аера иде* (Р.Низами. Без яшибез) [10]. Мондый мисаллар инглиз телендә дә байтак һәм, безнең фикеребезчә, аларны тикшерүгә багышланган аерым фәнни хезмәтләр булырга тиеш.

- Параметрик сыйфатларның төзелешенә килгәндә, аларның структур үзенчәлекләре һәр телнең, безнең очракта, татар һәм инглиз телләренең, үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә. Биредә уртак яклар күп, әмма аермалы яклар да юк түгел. Мәсәлән, татар телендә кешенең кыяфәтен, тән төзелешен тасвирлау, нигездә, кушма сыйфатлар ярдәмендә башкарыла. Мондый төр параметрик сыйфатлар **сүзтезмә** + ***-лы/-ле*** моделе буенча сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчү ысулы белән ясалалар: *озын кул**лы**, зур күз**ле**, кыска чәч**ле*** h.б.

- Параметрик сыйфатларның һәр ике телдә кулланылыш ешлыгына да игътибар ителде һәм нәтиҗәләр статистик алым ярдәмендә яктыртылып барылды. Гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, татар һәм инглиз телләрендә бу юнәлештә аермалы яклар күбрәк ачыкланды. Мәсәлән, һәр ике телдәге кешенең йөз-кыяфәтен тасвирлый торган сыйфатларның гомуми санына килсәк, татар телендә параметрик сыйфатларны белдергән сүзтезмәләр, инглиз теленә караганда, ике дистәгә кимрәк күзәтелә. Безнең фикеребезчә, әлеге күренешне кеше кыяфәтенә булган

игътибарсызлык итеп түгел, бәлки татарларның башка бер кешене тасвирлауда күрсәткән тотнаклылыгы дип аңларга кирәктер.

Димәк, параметрик сыйфатлар төркемен билгеләүдә төп нигез булып, предметларның номинатив үлчәмен тасвирлый торган сыйфатларны белдергән тел берәмлекләренең структур һәм семантик билгеләре белән бергә, аларның телдә кулланылыш үзенчәлекләре дә торырга тиеш.

**Әдәбият**

Апресян Ю.Д. Исследования по семантике и лексикографии. М.: Языки славянских культур, 2009. Т. 1. Парадигматика. 568 с.

Закамулина М.Н., Лутфуллина Г.Ф., Муллахметова Г.Р. Очерки по аспектологии. Проблема реализации частных значений (сопоставительное исследование на материале французского и татарского языков). Казань: Изд-во КГЭУ, 2016. 244 с.

Кузина И.Ю. О параметризации действительности языковыми средствами в художественном дискурсе (на примере эпистолярного жанра описания авантюрного путешествия) // Вестник Орловского государственного университета. Серия «Новые гуманитарные исследования». 2011. № 1 (15). С. 161-165.

Кустова Г.И. Типы производных значений и механизмы языкового расширения. М.: Языки славянской культуры, 2004. 472 с.

Письменный корпус татарского языка [Электронный ресурс]. URL: https://www.corpus.tatar/ (дата обращения: 26.08.2019).

British National Corpus [Электронный ресурс]. URL: http://www.natcorp.ox.ac.uk (дата обращения: 26.08.2019).

Cruse D. A. Lexical Semantics. Cambridge: Cambridge University Press, 1986. 234 p.

Dirven R., Taylor J. R. The Conceptualisation of Vertical Space in English: The Case of tall // Topics in Cognitive Linguistics / ed. by B. Rudzka-Ostyn. Amsterdam – Philadelphia: John Benjamins Publishing Company, 1988. P. 379-402.

Kennedy Ch., McNally L. Scale structure, degree modification, and the semantics of gradable predicates // Language. 2005. Vol. 81. № 2. P. 345-381.

Tatar National Corpus. Татарский национальный корпус «Туган тел» [Электронный ресурс]. URL: http://web-corpora.net/TatarCorpus/search/?interface_language=ru (дата обращения: 26.08.2019).

---

# ПРИМЕНЕНИЕ ПАРАМЕТРИЧЕСКИХ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫХ В ТАТАРСКОМ И АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ

**Гюльнара Фирдависовна Лотфуллина**,
Казанский государственный энергетический университет,
Россия, 420034, г. Казань, ул. Красносельская, д. 51,
gflutfullina@mail.ru.

**Рузиля Рашитовна Салахова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
ruzilya5@mail.ru.

**Гузель Зофаровна Гилязиева**,
Казанский государственный энергетический университет,
Россия, 420034, г. Казань, ул. Красносельская, д. 51,
gilyazieva78@mail.ru.

В статье в сравнительном аспекте изучаются параметрические прилагательные, которые используются для описания человека**.** Исследование прилагательных, характеризующих номинативные параметры предметов в татарском и английском языках, позволяет, с одной стороны, углубить наши представления о лексике, семантике обоих языков, а с другой стороны – выявить сходства и отличия разноструктурных языков, частоту их использования в языке. Этим и объясняется актуальность данного исследования.

Цель статьи – научное изучение своеобразия использования прилагательных, характеризующих внешность, одежду человека. Материалом исследования выступают адъективы, представляющие из себя крупные, широкие, короткие, длинные единицы. Для выяснения особенностей их использования в языке примеры берутся из татарского (Tatar National Corpus «Tugan Tel») и английского (British National Corpus) национального корпуса языков. На основании

фактологического материала, выявленного методом анализа корпусов, были определены прилагательные с положительной и отрицательной семантикой.

Практическая значимость данного научного исследования сводится к использованию его результатов в методике преподавания татарского и английского языков. Результаты настоящей работы можно применять при преподавании таких разделов языкознания, как лексикология, семасиология, стилистика.

**Ключевые слова:** история татарского языка, «Кысса-и Йусуф», тюркская лексика, религиозная лексика, булгарский период.